ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОЛЫЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КЕЧЕ ЛЫЗИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.03.2023 г. №19

«Чүпне, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм төрле эшләнмәләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 2018 елның 24нче декабре 19 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 24 октябрендәге 1885 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Чүпне, үләнне, яфракларны һәм башка калдыкларны, материалларны һәм төрле эшләнмәләрне яндыру урыннарын һәм ысулларын билгеләү турында» 24.12.2018 елның № 19 Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Преамбулада ««Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктчаны өстәргә:

«1.1. Торак пунктларның гомуми кулланылыштагы җирләрендә, шулай ук торак пунктлар территорияләрендә урнашкан хосусый йорт биләмәләрендә махсус бүлеп бирелгән һәм җиһазландырылган урыннардан читтә азык әзерләү өчен ачык ут куллану, шулай ук чүп, үлән, яфрак һәм башка калдыклар, материаллар яисә төрле эшләнмәләр яндыру тыела.»

2. Әлеге карар 2023 елныц 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль

районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Кече Лызи авыл җирлеге башлыгы А.С.Исмагилов